АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2019 № 226

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевскмуниципаль районында**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга , шул исәптән “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2 март, 2007 ел, 25 санлы Федераль законга, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 3 октябрь, 2018 ел, 382-ФЗ санлы Федераль законга туры китерү максатында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан РеспубликасыАлексеевскмуниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 19 сентябрь, 2018 ел, 193 нче Карары белән расланган түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

12.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасына яки коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашырга (сәяси партиягәидарә итүдә катнашудан,бушлай нигездә җирле үзидарә органында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела торган органына идарә итүдә катнашудан, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) катнашудан яки иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан,

бушлай нигездә күрсәтеп кителгән коммерциячел булмаган оешмаларга (сәяси партия һәм профессиональ берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасыннан кала) идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында катнашырга яки түләүсез нигездә катнашуга яисә

аларның кллегиаль органнары составына яллаучы вәкилнең (эш бирүченең) муниципаль хокук акты билгеләгән тәртиптә алынган рөхсәте белән керү.

1. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне башлык урынбасары Г.В. Беловага йөклим.

**Муниципальрайон башлыгы,**
**Советрәисе** **С.А. Демидов**